РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Аксубаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль
районы башкарма
комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

« 31 » 08 2020

№ 558

Аксубаево

Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми
белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган
төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы
муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә
сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләү түләү турында

Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 15.01.2020 елдагы Юлламасын тормышка ашыру буенча 24.01.2020 ел, №Пр-113 Йөкләмәләр исемлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү «Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 26.12. 2017 ел, №1642 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмаларының һәм муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләү билгеләү турында» 10.08.2020 ел, № 671 карары нигезендә, муниципаль белем бирү оешмаларында тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләү (алга таба - бүләкләү, гомуми белем бирү оешмалары) бер сыйныф җитәкчесенә аена 5000 сум күләмендә билгеләргә.

2. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларының

педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләклү түләү турында, кушымтада бирелгән, Нигезләмәне расларга.

3. Муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында түләүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында Һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru .

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Финанс бюджет палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының
«31» 08. 2020 № 558
карары белән расланган

Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата бүләкләү түләү турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата буләкләү (алга таба-бүләкләү, гомуми белем бирү оешмалары) билгеләү, түләү һәм аны түләү туктатылу шартларын билгели.
2. Бүләк педагогик хезмәткәрләргә сыйныфта (сыйныфларда), шулай ук класс-комплектта сыйныф җитәкчелеге өчен, ул, һәр сыйныфта укучылар санына бәйсез рәвештә, бер сыйныфка (алга таба - сыйныф) кабул ителә, шулай ук, җайлаштырылган гомуми белем бирү программаларын да кертеп, аларда гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү программалары, өчен түләнә.
3. Ике һәм аннан да күбрәк сыйныфларда сыйныфлар белән җитәкчелек итүче педагогик хезмәткәргә ике түләүдән дә артмыйча түләү билгеләнергә мөмкин.
4. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенең педагогик хезмәткәргә класс җитәкчесе функцияләрен йөкләү турындагы боерыгы педагогик хезмәткәркә бүләкләү билгеләү өчен нигез булып тора
5. Гомуми белем бирү оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы педагогик хезмәткәрләргә сыйныф җитәкчелеге өчен түләү педагогик хезмәткәрнең йөклелек һәм бала табу буенча отпусклары, бала карау буенча өч яшькә җиткәнче түләү туктатыла.
6. Бүләкләү күләме сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкаручы педагогик хезмәткәрнең педагогик йөкләнеше күләменә бәйле түгел. Бүләкләү күләме сыйныф җитәкчесе функцияләрен башкаручы педагогик хезмәткәрнең педагогик йөкләнеше күләменә бәйле түгел.
7. Бүләк уртача хезмәт хакы исәбенә кертелә.
8. Бүләк педагогик хезмәткәрләргә хезмәт хакы белән бер үк вакытта түләнә.
9. Уку елы дәвамында, каникуллар чорында, шулай ук санитар -

эпидемиологик, климат һәм башка нигезләр буенча укучылар өчен дәресләр гамәлдән чыгарылган (туктатылган) чорда педагогик хезмәткәрләргә түләү күләмен үзгәртү яки түләүне гамәлдән чыгару, педагогик хезмәткәр тарафыннан аның гаебе белән сыйныф җитәкчесе функцияләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

10. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе боерыгы педагогик хезмәткәргә бүләкләүне туктату һәм гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора.